**Казан шәһәре Думасының**
**2025 елның 26 мартындагы 10-37 номерлы карары**

**Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге объектлар урнаштыру территориаль зонасы (ОД) (33 номерлы контур) чикләрен үзгәртү өлешендә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең 20 статьясы нигезендә, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 3 февралендәге 219 номерлы «Казан шәһәре Думасының Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә территориаль зона – иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге объектларны урнаштыру зонасы (ОД) чикләрен үзгәртү өлешендә үзгәрешләр кертү турындагы карары проектын әзерләү хакында»гы карарын һәм 2025 елның 13 февраленнән алып 2025 елның 27 февраленә кадәр уздырылган җәмәгатьчелек белән фикер алышулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, Казан шәһәре Думасы **карар бирде**:

1. Казан шәһәре Думасының 2021 елның 16 августындагы 5-8 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә (алга таба – Кагыйдәләр) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасында, әлеге карарның 1 номерлы кушымтасы нигезендә 16:50:110701:699 кадастр номерлы, мәйданы 38132 кв.м булган җир кишәрлегенә карата территориаль зона – катнаш торак һәм иҗтимагый төзелеш зонасын (ОЖ) (58 номерлы контур) билгеләп,  территориаль зона – иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге объектлар урнаштыру зонасы (ОД) чикләрен үзгәртергә;

1.2. әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән территориаль зоналарның үзгәрә торган чикләрен Кагыйдәләр составында шәһәр төзелешен зоналаштыруның түбәндәге карталарында чагылдырырга:

- шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасы;
- территориаль зоналарның урам-юл челтәре, табигать-рекреация комплексы, махсус билгеләнештәге яшелләндерү, яр буе территорияләре ярдәмче зоналары күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы;

- территориаль зоналарның территориядән югары интенсивлыкта файдалану, шәһәр төзелешендә әһәмияткә ия территорияләр ярдәмче зоналары күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы;

- территориаль зоналарның ярдәмче зоналары: тарихи җирлек ярдәмче зонасы күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы;

- чикләрендә территорияләрне комплексы үстерүне гамәлгә ашыру күздә тотыла торган территорияләр картасы;

1.3. Кагыйдәләргә 1 номерлы кушымтаны әлеге карарга 2 номерлы кушымта нигезендә территориаль зоналар чикләре урнашу урынының график тасвирламасы белән тулыландырырга (хезмәт урынында файдалану өчен) (китерелми);


1.4. Кагыйдәләргә 2 номерлы кушымтаны әлеге карарга 3 номерлы кушымта нигезендә территориаль зоналар чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге белән тулыландырырга (хезмәт урынында файдалану өчен) (китерелми).

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга.

**Шәһәр Мэры** **И.Р.Метшин**

Казан шәһәре Думасының
2025 елның 26 мартындагы
10-37 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре составында шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасы фрагменты**




**Шартлы билгеләр:**

**ОД - 33**

Территориаль зона контурының тәртип номеры

Территориаль зона индексы

**Территориаль зона**

| Төс | Индекс | Территориаль зона төренең атамасы |
|---|---|---|
| | ОД | Иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге объектларны урнаштыру зонасы |
| | ОЖ | Катнаш торак һәм иҗтимагый төзелеш зонасы |
| | | Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре составында шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасы фрагменты чикләре |

**Башлык урынбасары** **Е.А.Лодвигова**